- Для уменьшения боли и отека к месту укуса на 10 минут приложите холод.

- Нанесите на место укуса кашицу, приготовленную из простой пищевой соды и воды. Можно смочить вату в растворе пищевой соды и приложить к месту укуса, чтобы уменьшить зуд (лучше привязать на 1-2 ч).

- Если припухлость в месте укуса очень выражена, зона покраснения более 10 см, отмечается выраженный зуд, примите противоаллергическое средство.

- Если сохраняется выраженный зуд, нарастает отек и увеличивается диаметр покраснения, следует немедленно обратиться к врачу.

- Старайтесь избегать мест роения пчел и ос. Не устраивайте пикники или привалы, если заметили рядом гнездо этих насекомых.



**Народные методы лечения укусов пчел, ос и шмелей**

1. Разжевать и приложить к пораженному месту листик подорожника.

2. Привязать к месту укуса листик одуванчика, предварительно помятый.

3. Прикрепить к пораженному месту листочки петрушки. Это устранит боль и припухлость.

4. Разрезать сырую луковицу и срезом прикрепить к месту укуса. Оставить на ночь.

**ТЕЛЕФОНЫ**

| | | |
|---|---|---|
| **ПОЖАРНЫЕ** | **101** | **01** |
| **ПОЛИЦИЯ** | **102** | **02** |
| **СКОРАЯ ПОМОЩЬ** | **103** | **03** |
| **ГАЗОВАЯ СЛУЖБА** | **104** | **04** |

**УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ЦЕНТР ПО ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЕ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# ПАМЯТКА

***Вас ужалило насекомое…***

***Что делать?***



**г. Нижнекам**

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 2 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН



Жало комара не опасно для человеческого организма, но комар является переносчиком различных заболеваний. После комариного укуса вместе с ядом в тело человека попадает вещество, которое не позволяет крови свертываться, что в свою очередь позволяет комару без препятствий принимать пищу. В результате небольшой аллергической реакции на месте укуса может появиться волдырь и покраснение.

## Что делать после укуса?

1. Сделать крепкий раствор пищевой соды и периодически обрабатывать зудящее место.
2. Смазать укусы спиртовой настойкой календулы, борным спиртом, томатным соком.
3. Сделать холодную примочку.
4. При множественных укусах принять антигистаминное средство (супрастин, цетрин)
5. В походной аптечке следует держать антигистаминный препарат (снимает зуд и даже устраняет ожоги крапивы).




## Народные методы

1. Обработать сметаной или кефиром.

2. Приложить к месту укуса лист черемухи или подорожника.

Жалящие насекомые кусают в целях самообороны. Жало следует тут же изъять из ранки. В месте укуса тело краснеет, припухает, болит и становится горячим.



## Что же делать и как себя вести, чтобы насекомые Вас не ужалили?

- Не нужно паниковать, размахивать руками, делать резких движений. Если пчела или оса летает вокруг Вас или села Вам на одежду или тело, надо спокойно дать пчеле обследовать Вас.

- На природе, где много цветов, не ходить босиком. В траве могут оказаться жалящие насекомые.

- Будьте осторожны при употреблении сладких продуктов и напитков на открытом воздухе.

- Старайтесь не носить слишком просторную одежду и распускать волосы - насекомое может запутаться в них и ужалить Вас.

- Не расчёсывайте поражённый участок, это способствует распространению яда.



Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 3 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- Авырту һәм шешүне киметү өчен, тешләү урынына 10 минутка салкын куегыз.

- Тешләү урынына гади азык содасы һәм судан торган катнашма сөртегез. Әрнүне киметү өчен, азык содасы эремәсенә мамык манып, аны тешләү урынына куерга мөмкин (1-2 сәгатькә бәйләп куюы яхшырак).

- Әгәр тешләгән урын бик нык шешсә, тире кызаруы 10 сантиметрдан артык тәшкил итсә һәм яра нык әрнегәндә, аллергиягә каршы дару эчегез.

- Әрнү бетмәгән, шешү зурайган һәм кызару диаметры киңәйгән вакытта ашыгыч рәвештә табибка мөрәҗәгать итегез.

- Бал корты һәм шөпшә ояларын читләп үтегез. Пикникка яки ял итәргә бу бөҗәкләр оялары янында туктамагыз.



## Бал корты, шөпшә һәм кормыш тешләвен дәвалауның халык ысуллары

1. Бака яфрагын чәйнәп, зарарланган урын өстенә куярга.

2. Тешләү урынына изелгән тузганак яфрагын бәйләп куярга.

3. Зарарланган урын өстенә петрушка яфрагын куярга. Бу авыртуны һәм шешүне бетерә.

4. Чи суган кисәргә һәм кискән җире белән тешләү урынына беркетеп куярга. Төнгегә калдырырга.

## ТЕЛЕФОННАР

| | | |
|---|---|---|
| **ЯНГЫНЧЫЛАР** | **101** | **01** |
| **ПОЛИЦИЯ** | **102** | **02** |
| **АШЫГЫЧ ЯРДӘМ** | **103** | **03** |
| **ГАЗ ХЕЗМӘТЕ** | **104** | **04** |

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ**

# БЕЛЕШМӘЛЕК

***Сезне бөҗәк чакты…***
***Нәрсә эшләргә?***



**Түбән Кама ш.**

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 4 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН



Черки угы кеше организмы өчен куркыныч түгел, әмма черки төрле авыруларны таратучы булып тора. Черки тешләгәннән соң, кеше тәненә агу белән бергә кан оешуга мөмкинлек бирми торган матдә ләгә, бу исә, үз чиратында, черкигә кан суырырга ярдәм итә. Тешләгән урында кечкенә аллергия реакциясе нәтиҗәсендә кабарчык һәм кызару барлыкка килергә мөмкин.

## Тешләгәннән соң нәрсә эшләргә?

1. Каты азык содасы эремәсе ясарга һәм вакыт-вакыт әрни торган җирне эшкәртергә.
2. Тешләү урыннарына спиртлы тырнак гөл төнәтмәсе, бор спирты, томат согы сөртергә.
3. Салкын примочка ясарга.
4. Тешләүләр күп булган чакта антигистамин даруы эчәргә (супрастин, цетрин).
5. Поход дару тартмасында антигистамин даруы булырга тиеш (ул әрнүне баса һәм хәтта кычыткан чагуын да бетерә).




## Халык ысуллары

1. Каймак яки кефир белән эшкәртергә.

2. Тешләү урынына шомырт яки бака яфрагы куярга.

Чагучы бөҗәкләр үзләрен саклау максатларында тешлиләр. Укны ярадан шунда ук чыгарырга кирәк. Тешләү урынында тән кызара, шешә, авырта һәм кыза.



## Бөҗәкләр Сезне чакмасын өчен нәрсә эшләргә һәм үзеңне ничек тотарга кирәк?

- Паникага бирелергә, кулларны болгарга, кискен хәрәкәтләр ясарга кирәкми. Әгәр дә бал корты яки шөпшә яныгызда оча икән, яки өстегезгә утырса, аңа үзегезне өйрәнеп чыгарга ирек бирегез.

- Табигатьтә күп чәчәкләр булган җирдә яланаяк йөрмәскә. Чирәмдә чага торган бөҗәкләр булырга мөмкин.

- Ачык һавада баллы ризык һәм эчемлекләр белән сак булыгыз.

- Артык киң кием кимәскә һәм чәчләрегезне туздырып йөрмәскә тырышыгыз – бөҗәк алар арасында буталып калып, Сезне чагырга мөмкин.

- Зарарланган җирне кашымагыз, бу агуның таралуына китерергә мөмкин.





Ливневые дожди, выпадающие в летние дни, часто сопровождаются грозами. Издавна гроза поражала воображение человека. Грозы приводили в ужас наших предков, плохо защищенных от непогоды. Пожары и смерть от ударов молнии производили и будут производить на людей сильное впечатление.



Особенно сильное впечатление производит гроза, которая разразилась «прямо над головой», когда непрерывно грохочет гром, когда бушует ураганный ветер и из грозно клубящихся облаков хлещет ливень.

Молния опасна тогда, когда вслед за вспышкой следует раската грома. В этом случае срочно примите меры предосторожности.

# ЕДИНАЯ СЛУЖБА СПАСЕНИЯ

# 112

| | | |
|---|---|---|
| **ПОЖАРНЫЕ** | 101 | 01 |
| **ПОЛИЦИЯ** | 102 | 02 |
| **СКОРАЯ ПОМОЩЬ** | 103 | 03 |
| **ГАЗОВАЯ СЛУЖБА** | 104 | 04 |

**УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ЦЕНТР ПО ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЕ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# ПАМЯТКА ДЛЯ НАСЕЛЕНИЯ

## Действия во время грозы



**г. Зеленодол**

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 6 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## Во время ударов молнии:

- *не находитесь близко к электропроводке, молниеотводу, водостокам крыш, антенне;*
- *не стойте рядом с окном;*
- *по возможности выключите телевизор, радио и другие электробытовые приборы*



## Если вы находитесь в сельской местности:

- *закройте окна, двери, дымоходы и вентиляционные отверстия;*
- *не разговаривайте по телефону: молния иногда падает в натянутые между столбами провода.*



## Если гроза застала вас в автомобиле:

- *не покидайте его, при этом закройте окна и опустите антенну радиоприемника.*



## Если вы находитесь в лесу:

- *укройтесь на низкорослом участке леса;*
- *не укрывайтесь вблизи высоких деревьев, таких как сосны, дубы и тополя;*
- *не находитесь в водоеме или на его берегу.*
- *отойдите от берега, с возвышенного места в низину.*



## Если вы находитесь на открытой местности:

- *сядьте на корточки в ложбине, овраге или другом естественном углублении, обхватив ноги руками*

Җәйге көннәрдә ява торган койма яңгырлар еш кына яшенле була. Элек-электән яшен кешенең карашын таң калдыра иде. Явым-төшемнәрдән начар якланган ата-бабаларыбыз койма яңгырлардан бик курка иде. Янгыннар һәм яшен сугудан үлемнәр кешеләргә гел көчле тәэсир ясый иде һәм ясыячак та.



Бигрәк тә “кинәт баш өстендә” барлыкка килгән яшен көчле тәэсир ясый, туктаусыз күк күкрәгәндә, көчле давыл җиле искәндә һәм кара болытлардан ишеп койма яңгыр яуганда.

Яшен, ялтыраудан соң күк күкрәве яңгыраган чакта куркыныч. Бу очракта кичекмәстән саклык чараларын күрегез.

# БЕРДӘМ КОТКАРУ ХЕЗМӘТЕ

# 112



| | | |
|---|---|---|
| **ЯНГЫНЧЫЛАР** | 101 | 01 |
| **ПОЛИЦИЯ** | 102 | 02 |
| **АШЫГЫЧ ЯРДӘМ** | 103 | 03 |
| **ГАЗ ХЕЗМӘТЕ** | 104 | 04 |

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ**

# ХАЛЫК ӨЧЕН БЕЛЕШМӘЛЕК

## Яшен вакытында куркынычсызлык кагыйдәләре



**Яшел Үзән ш.**

**Яшен суккан вакытта:**

- *антеннага, түбә сутөшергечена, яшен кайтаргычына якын тормагыз;*
- *тәрәзәгә якын килмәгез;*
- *мөмкин булганча телевизор, радио һәм башка электр-көнкүреш приборларын сүндерегез*



**Авыл җирендә булган чакта:**

- *тәрәзәләрне, ишекләрне, төтен һәм вентиляция юлларын ябыгыз;*
- *телефоннан сөйләшмәгез: яшен кайчагында баганалар арасында сузылган чыбыкларга ләгә.*



**Әгәр автомобильдә булган чакта яшен башланса:**

- *машинадан чыкмагыз, тәрәзәләрне ябыгыз һәм радио антеннасын төшерегез.*



**Урманда булган чакта:**

- *урманның түбән агачлы җирендә качыгыз;*
- *нарат, имән һәм тирәк кебек югары агачлар янында тормагыз;*
- *сулыклар эченнән һәм ярларыннан китегез;*
- *ярдан, калкулыктан түбәнлеккә китегез.*



**Ачык урында булган чакта:**

- *уйсулыкта, чокырда яки бүтән тирән урында аякларыгызны кочаклап чүгәләгез.*





**УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ЦЕНТР ПО ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЕ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# Памятка

## *Берегите лес от пожара!*



г. Альметьевск

# ЛЕСНОЙ ПОЖАР



**- самопроизвольное или спровоцированное человеком возгорание в лесных экосистемах.**

## Алгоритм действий

**1. Не паниковать и постараться максимально грамотно оценить площадь, место и силу возникшего очага огня.**





**2. При небольшом очаге возгорания принять доступные меры к тушению (водой, вениками из зеленых веток). При наличии инструмента забросать землей кромку пожара.**



## Если ситуация вышла из-под контроля



**Надо определить направление ветра и выбрать направление движения - против ветра, перпендикулярно к линии огня.**

**3. Чтобы не обгореть, смочить водой одежду, волосы, открытые участки тела.**





**4. Если возможно, перебраться на другой берег реки (ручья), окунуться в водоём.**

**5. При сильном задымлении двигаться пригнувшись, прикрыв нос и рот куском смоченной ткани, сделав глубокий вдох.**

**6. Учитывать, что во время движения серьезную опасность могут представлять падающие деревья.**



**7. После выхода из зоны, охваченной огнем, сообщить органам МЧС России по телефону 112.**




**В случае пожара**
**ЗВОНИТЕ**
**по телефонам:**
**112 или 101**



Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 11 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН





**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ**

**Белешмәлек**

# *Урманны янгыннан саклагыз!*



Әлмәт ш.

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 12 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

# УРМАН ЯНГЫНЫ



**- урман экосистемаларында кеше тарафыннан яки үз ихтыяры белән янгын чыгу.**

## Гамәлләр алгоритмы

**1. Паникага бирелмәскә һәм утның мәйданын, урынын һәм көчен максималь дәрәҗәдә дөрес бәяләргә тырышырга.**



**2. Кечкенә мәйданда янгын булган очракта сүндерү чаралары күрергә: су, яшел ботаклардан себеркеләр. Һәм инструмент булган очракта, янгын кырыен җир белән күмәргә.**





## Әгәр вәзгыять контрольдән чыкса



**Җил юнәлешен билгеләп хәрәкәт юнәлешен карарга кирәк: җилгә каршы, янгын сызыгына перпендикуляр рәвештә.**

**3. Тән пешүе алмас өчен, су белән киемне, чәчне һәм ачык тән өлешләрен суларга.**





**Мөмкин булган очракта, елганың (инешнең) икенче ярына күчәргә, сулыкка чумарга.**

**4. Көчле төтен чыккан очракта, борын һәм авызны юеш чүпрәк кисәге белән каплап, тирән сулап хәрәкәт итәргә.**

**5. Хәрәкәт вакытында аучы агачлар куркынычы турында истә тотарга.**



**6. Янгын белән капланган зонадан чыкканнан соң, Россия ГТХМ органнарына 112 телефоны буенча хәбәр итәргә.**









ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН


## ПОСЛЕ УКУСА!

**Не сдавливайте тело клеща**

**Не поливайте его маслом и керосином**

**Не вынимайте клеща пальцами**

**Насекомое осторожно вытягивают за брюшко, слегка раскачивая, пинцетом или с помощью петли из прочной нити, накинутой как можно ближе к хоботку**



**Достать клеща (Лучше обратиться в медицинское учреждение)!!!**


**Обратиться к врачу для проведения необходимой профилактики!!!**

## ПЕРИОД АКТИВНОСТИ –



## С МАРТА ПО НОЯБРЬ!!!

## ЧТО ДЕЛАТЬ С КЛЕЩЕМ!




**Его можно принести на лабораторное исследование в:**

**«Центр гигиены и эпидемиологии в Республике Татарстан»**

**по адресу:**
**г. Казань, ул. Сеченова, д. 13 А**
**Тел. 221-79-12, 221-79-79**

**Телефон единой службы спасения**




**УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ЦЕНТР ПО ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЕ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

## ПАМЯТКА ДЛЯ НАСЕЛЕНИЯ

# КАК ЗАЩИТИТЬ СЕБЯ ОТ УКУСА ЛЕСНОГО КЛЕЩА?



**г. Казань**


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## ПРАВИЛЬНО ОДЕВАЙТЕСЬ!

Обязательно наденьте головной убор, волосы заправьте под косынку

Воротник и манжеты должны плотно прилегать к телу



Носите светлую, однотонную одежду

Брюки заправьте в ботинки или в носки с плотной резинкой

Нанесите на одежду репеллентное средство от клещей!!!

## ЛИЧНАЯ ЗАЩИТА!



Не садиться и не ложиться на траву

Проводить само- взаимо осмотры каждые 10-15 минут для обнаружения клещей

Не заносить в помещение свежие сорванные растения

Самая надежная мера защиты – это заблаговременная вакцинация (прививка)!!!



## ПОСЛЕ ПРОГУЛКИ!

Снять одежду

Тщательно осмотреть тело и одежду





Расчесать волосы мелкой расческой



## ТЕШЛӘГӘННӘН СОҢ!

Талпанның гәүдәсен сытмагыз
Аңа май һәм керосин сипмәгез
Талпанны бармакларыгыз белән тартып чыгармагыз
Пинцет яки нык җептән ясалган, хортумга мөмкин кадәр якынрак урнаштырылган элмәк белән әкрен генә чайкый-чайкый бөҗәкне сак кына корсагыннан тартып алалар




Талпанны алу
(Медицина учреждениесенә мөрәҗәгать итү яхшырак)!!!

Кирәкле профилактика үткәрү өчен табибка мөрәҗәгать итәргә!!!

## АКТИВЛЫК ЧОРЫ –



## МАРТТАН НОЯБРЬГӘ КАДӘР!!!




**ПАНИКАГА БИРЕЛМӘ!**
**Талпанны лабораториягә анализга тапшыр.**
**Аны лаборатория тикшерүенә «Татарстан Республикасы гигиена һәм эпидемиология үзәгенә» алып килергә мөмкин.**

**Казан ш., Сеченов ур., 13А й.**
**Тел. 221-79-12, 221-79-79**

**Бердәм коткару хезмәте телефоны**




**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ**

**ХАЛЫК ӨЧЕН БЕЛЕШМӘЛЕК**

# УРМАН ТАЛПАНЫ ТЕШЛӘВЕННӘН ҮЗЕҢНЕ НИЧЕК САКЛАРГА?



**Казан ш.**


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## ДӨРЕС КИЕНЕГЕЗ!

**Баш киеме киегез, чәчегезне яулык астына җыегыз**

**Якалар һәм манжетлар тәндә тыгыз утырырга тиеш**



**Якты һәм бер төстәге кием киегез**

**Чалбарны аяк киеменә яки тыгыз резинкалы оекбашларга кыстырыгыз**

**Киемгә талпаннардан репеллент сыекча сибегез!!!**

## ШӘХСИ САКЛАНУ!



**Чирәмгә ятмаска һәм утырмаска**

**Талпаннарны табу өчен һәр 10-15 минут саен үз – үзеңне һәм башкаларны карап чыгарга**





**Бүлмәгә яңа өзгән үсемлекләр алып кермәскә**

**Иң ышанычлы саклану чарасы – алдан ук вакцинация үтү (прививка кую)!!!**



## УРАМДА ЙӨРГӘННӘН СОҢ!

**Киемне салырга**

**Тән һәм киемне җентекләп карап чыгарга**




**Талпан кая тешли?**
**Баш, колак арты, култык асты, касык, тез асты.**

**ЧӘЧНЕ ВАК ТАРАК БЕЛӘН ТАРАП ЧЫГАРГА**



## Меры предосторожности от укусов змей:




## *ПОМНИ!*

## *ЕСЛИ ПРОИЗОШЛА БЕДА*




| | |
|---|---|
| **ПОЖАРНЫЕ** | **101 01** |
| **ПОЛИЦИЯ** | **102 02** |
| **СКОРАЯ ПОМОЩЬ** | **103 03** |
| **ГАЗОВАЯ СЛУЖБА** | **104 04** |

**УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ЦЕНТР ПО ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЕ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# Памятка для населения
# Осторожно, змеи



**г. Бугульма**

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 20 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01

**Змеи крайне редко сами нападают на человека. Чаще всего укусы люди получают по неосторожности – случайно наступив или зацепив змею. Чтобы избежать агрессии со стороны пресмыкающихся, нужно быть внимательными в лесу и знать, как выглядит каждый вид змей.**

## Меры предосторожности от укусов змей

- Отправляясь в лес, лучше всего надеть обувь с высоким голенищем, а брюки – длинные и из плотной ткани
- Присаживаясь отдохнуть, осмотреть место отдыха



Обыкновенный уж




Обыкновенная гадюка естественная ядовитая змея



## Симптомы укуса

- В области укуса пострадавший чувствует сильную боль
- Из ранки выступает несколько капелек крови
- Спустя час или два может появиться чувство холода, затрудненное дыхание, сильная жажда, нитевидный пульс, обмороки, судороги, бред

## Первая помощь

- необходимо удалить яд из ранки
- по возможности создать покой укушенной конечности
- поместить ее в возвышенное положение
- пострадавшего укутать в теплую одежду, дать обильное питье
- быстро доставить его в больницу


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## Елан тешләүдән саклык чаралары:



Еланнарга басмаска



Шорт түгел, ә чалбар кияргә



Яланаяк яки ачык аяк киемендә йөрергә ярамый



## *ИСТӘ ТОТ!*

## *ӘГӘР БӘЛА КИЛЕП ЧЫКСА*

112
Единый телефон спасения

**БЕРДӘМ КОТКАРУ НОМЕРЫ**

| | |
|---|---|
| ЯНГЫНЧЫЛАР | 101 01 |
| ПОЛИЦИЯ | 102 02 |
| АШЫГЫЧ ЯРДӘМ | 103 03 |
| ГАЗ ХЕЗМӘТЕ | 104 04 |

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ**

# Халык өчен белешмәлек

# Сак булыгыз, еланнар



**Бөгелмә ш.**

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.

Еланнар бик сирәк кешегә үзләре һөҗүм итә. Еш кына кешеләрне саксызлык аркасында тешлиләр - елан өстенә ялгыш басу яки аны ләктереп киту нәтиҗәсендә. Бәхетсезлек очрагын булдырмас өчен, урманда игътибарлы булырга һәм еланнарның һәр төре нинди була икәнен белергә кирәк.

## Елан тешләүдән саклык чаралары

- Урманга барган чакта, биек аяк киеме һәм тыгыз тукымадан тегелгән озын чалбар киюэ яхшырак.
- Ял итәргә утырганда, ял урынын карап чыгыгыз.



Гади тузбаш



Тешләү урыннары: кул бармаклары, кул, балтыр, аяк табаны.

Гади кара елан табигый агулы елан



Гади бакыр елан

## Тешләү симптомнары

- Тешләү җирендә зыян күрүче көчле авырту сизә.
- Ярада берничә тамчы кан күренә.
- 1-2 сәгатьтән соң туңу тойгысы, авыр сулыш, көчле сусау, сирәк пульс, һуш киту, күзән җыеру, саташу очраклары барлыкка килә ала.

## Беренче ярдәм

ярадан агуны чыгарырга кирәк

мөмкин булганча тешләнгән җирне хәрәкәтсез тотарга

аны күтәребрәк тотарга

зыян күрүчене җылы юрган белән урарга, күп итеп су бирергә

аны тизрәк хастаханәгә җиткерергә

## ПРАВИЛА СБОРА:

Собирайте только те грибы, которые хорошо знает.

Не собирайте их в черте города, а также вблизи свалок, скоплений мусора и у дороги. Грибы - природные “пылесосы” и замечательно впитывают в себя вредные вещества.

Не собирайте старые переросшие и червивые грибы, ими также можно отравиться.

Не пробуйте сырые грибы на вкус.

Не верьте утверждению, что яд из грибов можно удалить, если кипятить их несколько часов, чаще всего яды термостойки.



## ПРИЗНАКИ ОТРАВЛЕНИЯ ГРИБАМИ:

- боль в животе,
- головная боль,
- тошнота,
- рвота,
- понос,
- слабость,
- обильный пот,
- изменение температуры тела (она может не повыситься, а, наоборот, резко понизиться).

При сильном отравлении, особенно ядом мухоморов и бледной поганки, возможны бред, галлюцинации, потеря сознания.

Первые признаки грибного отравления обычно проявляются уже через полчаса после еды, самое позднее – спустя 4 часа.

## ПЕРВАЯ ПОМОЩЬ:

- Вызвать скорую помощь
- Очистить желудок (вызвать рвоту)
- Уложить в постель и укрыть теплым одеялом
- Чаще поить кипяченой водой
- Прием пищи запретить
- Не давать лекарства до приезда врачей

## ЕДИНАЯ СЛУЖБА СПАСЕНИЯ

**112**

| | | |
|---|---|---|
| **ПОЖАРНЫЕ** | 101 | 01 |
| **ПОЛИЦИЯ** | 102 | 02 |
| **СКОРАЯ ПОМОЩЬ** | 103 | 03 |
| **ГАЗОВАЯ СЛУЖБА** | 104 | 04 |

**УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ЦЕНТР ПО ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЕ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# ПАМЯТКА ДЛЯ НАСЕЛЕНИЯ

## *Ядовитые грибы*



**г. Набережные Челны**

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 24 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

# ПОМНИ:

### Ложные опята



У съедобных опят шляпка коричневато-желтая, на ножке пленка, похожая на кольцо. У **ложных опят** желто-зеленая или красноватая шляпка, а на ножке нет кольца.

### Ложная лисичка



У настоящей лисички края шляпки выгнутые, гофрированные, цвет яично-желтый или оранжево-желтый, а у ложной - шляпка округлая, воронкообразная, с ровными краями, цвет красновато-оранжевый, красно-медный.

### Желчный гриб



У самого ценного гриба-**белого** - есть опасные двойники: сатанинский и желчный. Отличаются они от белого тем, что у них нижняя сторона шляпки не белая или желтоватая, как у боровика, а розовая или даже красная. Если разломить шляпку белого гриба, она не изменит своего цвета, а у этих грибов вначале покраснеет, потом почернеет.

**Наиболее опасного двойника** имеют шампиньоны. Это смертельно ядовитая **бледная поганка** Ножка у неё будто вылезает



из горлышка широкого горшочка. В верхней части ножки есть пленчатое кольцо. На корне у бледной поганки есть характерный мешочек. Ядовитые свойства этого гриба сохраняются при любой обработке: и при сушке, и при варке, и при засолке.



**Второй двойник-**

**шампиньон желтокожий** (рыжеющий), на изломе мякоть его рыжеет и пахнет карболкой.

### Красный мухомор



Ядовитый **красный мухомор,** к счастью, не похож ни на один съедобный гриб.

## ЗАПОМНИТЕ

***отличительные признаки***

***ядовитых и несъедобных***

***грибов:***

- белые точки или чешуйки на верхней стороне шляпки;
- клубневидное утолщение у основания ножки;
- пленка под шляпкой (за исключением опят, маслят и шампиньонов, это съедобные);
- чешуйки на нижней стороне ножки;
- резкое, ярко выраженное клубневидное утолщение у основания ножки;
- нижняя поверхность шляпки – розовая или красноватая.

## ҖЫЮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ:

Үзегез яхшы белгән гөмбәләрне генә җыегыз.

Аларны шәһәр эчендә, чүплекләр, чүп-чар җыелмасы арасында һәм юл янында җыймагыз. Гөмбәләр - табигый "тузансуырткычлар", зарарлы матдәләрне бик яхшы сеңдерәләр.

Иске, артык үскән һәм кортлаган гөмбәләрне җыймагыз, алар белән шулай ук агуланырга була.

Чи гөмбәләрне тәмен белү максатларында кабып карамагыз.

Берничә сәгать кайнатканнан соң гөмбәләрдән агуны бетереп була торган фикергә ышанмагыз, агулар еш кайнарга чыдамлы.



## ГӨМБӘ БЕЛӘН АГУЛАНУ БИЛГЕЛӘРЕ:

- эч авыртуы,
- баш авыртуы,
- күңел болгану,
- косу,
- эч китү,
- көчсезлек,
- каты тирләү,
- тән температурасы үзгәрү (ул артмаска,ә киресенчә, кискен кимергә мөмкин).

Көчле агуланганда, бигрәк тә чебен гөмбәсе агуы һәм төссез агулы гөмбә агуы белән, саташу, галлюцинация, аңны югалту ихтималы бар.

Гөмбә белән агулануның беренче билгеләре, гадәттә, ашаганнан соң ярты сәгатьтән соң, соңрагы – 4 сәгатьтән соң ачыклана.

## БЕРЕНЧЕ ЯРДӘМ:

- Ашыгыч ярдәм чакыртырга
- Ашказанын чистартырга (костырырга)
- Яткырырга һәм җылы юрган белән ябырга
- Ешрак кайнаган су эчерергә
- Ашарга бирмәскә
- Табиблар килгәнче дару бирмәскә

## БЕРДӘМ КОТКАРУ ХЕЗМӘТЕ

**112**

| | | |
|---|---|---|
| ЯНГЫНЧЫЛАР | 101 | 01 |
| ПОЛИЦИЯ | 102 | 02 |
| АШЫГЫЧ ЯРДӘМ | 103 | 03 |
| ГАЗ ХЕЗМӘТЕ | 104 | 04 |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ

# ХАЛЫК ӨЧЕН БЕЛЕШМӘЛЕК

## *Агулы гөмбәләр*



**Яр Чаллы ш.**


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

# ИСТӘ ТОТ:

### Ялган баллы гөмбә



Ашый торган баллы гөмбәнең эшләпәсе көрән-сары төстә, аягында балдакка охшаган элпә. **Ялган баллы гөмбәнең** эшләпәсе сары-яшел яки кызыл, ә аягында балдагы юк.

### Ялган әтәч гөмбәсе



Чын әтәч гөмбәсенең эшләпәсе кырыйлары бөгелгән, сызык-сызык текстуралы, төсе йомырка сыман сары яки кызгылт-сары, ә ялганның эшләпәсе түгәрәк, бүрәнкә сыман, тигез кырыйлы, төсе кызыл-кызгылт, кызыл-бакыр.

### Үтле гөмбә



Иң кыйммәтле гөмбәнең – **ак** гөмбәнең – куркыныч охшашлары бар: сатаник һәм үтле гөмбәләр. Алар ак гөмбәдән аерыла: эшләпәләре аскы ягы нарат гөмбәсенеке кебек ак яки сары түгел, ә алсу яки хәтта кызыл була. Әгәр дә ак гөмбәнең эшләпәсен ярсак, ул үз төсен үзгәртмиячәк, ә тегеләрнеке баштан кызара, аннары каралачак.

**Тагын да куркынычрак игезәккә** шампиньоннар ия. Бу үлемгә китерә торган



агулы **төссез агулы гөмбә.** Аның аягы киң чүлмәк авызыннан чыккан сыман. Аягының өске өлешендә элпә балдак бар. Тамырында үзенчәлекле капчыгы бар. Бу гөмбәнең агулы сыйфатлары теләсә нинди эшкәртүдән соң саклана: киптергәннән, пешергәннән, тозлаганнан соң.



**Икенче игезәк - сары тәнле шампиньон** (жирәнләнүче), яргач аның йомшагы жирәнләнә һәм карбол исе килә.



### Кызыл чебен гөмбәсе

Бәхеткә, агулы **Кызыл чебен гөмбәсе** бер генә ашарга яраклы гөмбәгә дә охшамаган.

## <u>ИСТӘ ТОТЫГЫЗ</u>

***агулы һәм ашарга яраксыз гөмбәләрнең аеру билгеләре:***

- эшләпәсенең өске ягында ак нокталар яки тәңкәләр;
- аягы нигезендә бүлбе сыман калынлык;
- эшләпәсе астында элпә (баллы гөмбә, майлы гөмбә һәм шампиньоннардан башка, алар ашарга яраклы);
- аягының аскы ягында тәңкәләре бар;
- аягы нигезендә күзгә ташлана торган бүлбе сыман калынлык;
- эшләпәсенең аскы өслеге алсу яки кызыл төстә;

# ЕДИНЫЙ
# телефон спасения

112



**УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ЦЕНТР ПО ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЕ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# Правила безопасного поведения на воде



г. Альметье

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 28 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН



**Не купайтесь в неизвестных и не предназначенных для этой цели водоёмах!**




**Купаться можно только в специально оборудованных местах!**



**Не купайтесь в штормовую погоду, берегитесь волн!**



**Не заплывайте далеко от берега на надувных матрасах, автомобильных камерах!**



**Не переохлаждайтесь и не перегревайтесь!**
**Не купайтесь при температуре воды ниже 18˚С, воздуха - ниже 22˚С.**



Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 29 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

# Бердәм коткару телефоны

112



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ

# Суда куркынычсызлык кагыйдәләре



Әлмәт ш.

Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 30 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН




**Бу максат өчен билгеләнмәгән һәм билгесез сулыкларда коенмагыз!**




**Махсус җиһазландырылган урыннарда гына коенырга була!**



**Шторм вакытында коенмагыз, дулкыннардан саклангыз!**



**Кабарынкы матрас, автомобиль камераларында ярдан ерак йөзмәгез!**



**Өшемәгез һәм кызмагыз! Су температурасы 18 градустан һәм һава температурасы 22 градустан түбән булганда коенмагыз.**



Документ создан в электронной форме. № 4171/Т10-36-1-15 от 07.07.2022. Исполнитель: Файрушина Д.Х.
Страница 31 из 32. Страница создана: 07.07.2022 15:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН